Татарстан РеспубликасыТүбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлеге составына керүче Кушай торак пунктында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елның 26 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Шәңгәлче авыл җирлегенең Кушай торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Түбән Кама муниципаль районының Шәңгәлче авыл җирлеге Кушай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган яшәүчедән, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире/хатыннардан тыш; күрсәтелгән сумманың 50% күләмендә 2 группа инвалидлар һәм 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар түлиләр, 1000 сум күләмендә 2023 елда үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны
-су коесына тирән насос һәм автоматика алу юнәлдерергә,
-Кушай авылының Үзәк урамы буйлап юлны ремонтлау (шул исәптән инерт материаллар сатып алу, ташу, салу, тигезләү һ. б.),
-зират коймасы.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Шәңгәлче авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Сәлимов